# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында**

<u>1 статья.</u> «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, № 12; 1999 ел, № 6, № 9, № 12) түбәндәге редакциядә $12^1$ статьяны өстәргә:

«<u>$12^1$ статья.</u> Җаваплылыгы чикләнгән «Татарстан аграр-промышленность банкы» җәмгыятенең устав капиталында дәүләт (Татарстан Республикасы) өлешен арттыру өчен Татарстан Республикасының республика бюджетыннан 60 млн. сум күләмендәге ассигнованиеләрне расларга.

Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнарына, Татарстан Республикасының республика бюджетында берләштерелгән максатчыл бюджет фондларына, дәүләт (республика) предприятиеләренә, учреждениеләренә һәм оешмаларына җаваплылыгы чикләнгән «Татарстан аграр-промышленность банкы» җәмгыятендә катнашучылар булуны рөхсәт итәргә.

<u>2 статья.</u> Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 29 июне
№ 233